| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 14 марты № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгының «2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 13 декабрендәге 24 номерлы карары белән расланган бюджет керемнәренең Баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясындагы 3[2] пунктының өченче абзацы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Түбән Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

926 бүлек Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең «Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесе:

| | | |
|---|---|---|
| 926 | 1 17 16000 10 0000 180 | Авыл җирлекләре бюджетларының авыл җирлеге бюджетының бердәм счетына кертелгән көннән алып өч елдан да соңга калмыйча аларны кире кайтару (төгәлләштерү) башкарылмаган ачыкланмаган кертемнәр өлешендә башка салым булмаган керемнәре |

| | | |
|---|---|---|
| 926 | 2 02 49999 10 0000 150 | Авыл җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Түбән Чыршылы авылы, Түбән Чыршылы авылы административ бинасында-Үзәк урамы, 105 йорт, балалар бакчасы бинасында-Совет урамы, 8 йорт, Үзәк урамы, 23нче йорт янында, «АФ-Спартак» ҖЧҖ идарәсе бинасында-Совет урамы, 2нче йорт , Югары Чыршылы авылында-авыл клубы бинасында-Горная урамы, 27нче йорт, Мордва Ивановкасы авылында-Совет урамы, 13нче йорт адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) "Авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
бәрәмлеге башлыгы Н.Я.Хәйруллина